| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** 20.09.2017 | г. Казань | **БОЕРЫК** №1111-п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының ведомство бүләкләре турында

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексы, 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” Федераль закон, 2003 елның 16 январендагы 3-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 325 нче номерлы “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре” карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турында нигезләмә нигезендә һәм экология һәм табигать саклау өлкәсе хезмәткәрләрен бүләкләү максатында, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга:

А.И. Щеповских исемендәге медаль;

“Татарстан Республикасының табигать саклау отличнигы” күкрәк билгесе;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Почет грамотасы;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Рәхмәт хаты.

2. Кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының (алга таба – Министрлык) ведомство бүләкләре турында нигезләмәне расларга.

3. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Ш.К. Сәлимгәрәев) бүләкләү документларын кабул итү, бүләкләүгә материалларны әзерләү, ведомство бүләкләрен рәсмиләштерү һәм бирү, аларның исәбен алып бару буенча эшне оештырырга.

4. Финанс контроле, исәп һәм хисаплылык бүлегенә (С.А. Яковлева) һәр елны Министрлык сметасында Министрлыкның ведомство бүләкләре бланкларын әзерләүне финанслауга чыгымнарны күздә тотарга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен котрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр Ф.С.Габделганиев

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 2017елның 20 сентябрендәге № 1111-п боерыгы белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ ВЕДОМСТВО БҮЛӘКЛӘРЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының ведомство бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү тәртибен (алга таба тиешенчә – Министрлык, ведомство бүләкләре), ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибен һәм ведомство бүләкләре тасвирламасын билгели.

1.2. Ведомство бүләкләре әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән затларның казанышларын хуплау һәм иҗтимагый тану формасы булып тора.

1.3. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү хезмәттәге югары казанышлар һәм табигый ресурсларны файдалану, әйләнә-тирә табигый мохитне саклау, геологик-разведкалау һәм геодезия эшчәнлеге өлкәсендәге мәсьәләләрне чишүгә иҗади якын килгән өчен, экологик белем бирү системасын оештыру һәм үстерүдә, Татарстан Республикасы территориясендә экологик культура формалаштырудагы казанышлар өчен, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә республика, федераль максатчан программаларын эшләү һәм тормышка ашыру эшенә зур өлеш керткән өчен башкарыла.

1.4. Ведомство бүләкләре белән бүләкләнүгә кадидатлар түбәндәге таләпләргә берьюлы туры килергә тиеш:

1.4.1. Эш стажы булу:

әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән тиешле эшчәнлек өлкәсендә 10 елдан ким түгел – «А.И. Щеповских ис. медаль» (алга таба – Медаль) белән бүләкләү өчен;

әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән тиешле эшчәнлек өлкәсендә 10 елдан ким түгел – «Татарстан Республикасының табигать саклау отличнигы» күкрәк билгесе белән бүләкләү өчен (алга таба – күкрәк билгесе);

әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән тиешле эшчәнлек өлкәсендә 5 елдан ким түгел – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Почет грамотасы белән бүләкләү өчен (алга таба – Почет грамотасы);

бүләкләүгә тәкъдим итә торган оешмада (органда) 1 елдан ким түгел – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләү өчен (алга таба – Рәхмәт хаты).

1.4.2. Тиешле эшчәнлек өлкәсендә һөнәри казанышлар булу (нәтиҗәле һәм намуслы хезмәт эшчәнлеге өчен бүләкләр һәм бүләкләүләр турында мәгълүмат);

1.4.3. Закон белән билгеләнгән тәртиптә алынмаган яки бетмәгән хөкем ителгәнлек булмау;

1.4.4. Алынмаган дисциплинар җәза булмау.

1.5. Оешма (орган) ликвидацияләнгән (бетерелгән) яки оешма (орган) хокук һәм йөкләмәләрне (функция һәм вәкаләтләрне) башка юридик затка тапшырып реорганизацияләнгән очракта, кадидатның эш (хезмәт) стажы саклана һәм аның үтенеч бирүче оешмада (органда) эш (хезмәт) стажына таләпләргә туры килүе билгеләнгәндә, өзлексез дип санала.

## II. ВЕДОМСТВО БҮЛӘГЕ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮГӘ ТӘКЪДИМ ИТҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Ведомство бүләге белән бүләкләү турында үтенеч кузгату турында карар бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затның төп эш (хезмәт) урыны буенча коллектив тарафынннан кабул ителә. Ведомство бүләгенең төре бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затның казанышлары дәрәҗәсен һәм характерын һәм әлеге Нигезләмәне искә алып билгеләнә.

2.2. Ведомство бүләкләре белән бүләкләү түбәндәге эзлеклелектә гамәлгә ашырыла:

Медаль белән элегрәк Почет грамотасы белән бүләкләнгән хезмәткәрләр бүләкләнә. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә стажы 15 елдан артык булган хезмәткәрләр чыгарма булып тора.

Күкрәк билгесе белән элегрәк Почет грамотасы белән бүләкләнгән хезмәткәрләр бүләкләнә. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә стажы 10 елдан артык булган хезмәткәрләр чыгарма булып тора.

Дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен, предприятиеләр һәм оешмалар хезмәткәрләрен Почет грамотасы белән бүләкләү өчен түбәндәге юбилей даталары билгеләнә: 50, 55, 60, 65, 70 яшь һәм шулай алга таба.

Почет грамотасы белән экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсен үстерүдә әһәмиятле уңышларга ирешкән оешмаларның һәм предприятиеләрнең хезмәткәрләре, коллективлары, әйләнә-тирә мохитне саклауның нәтиҗәлелеген күтәрүгә этәргеч бирә торган яңа техника һәм технологияләр, уйлап табулар һәм рационализаторлык тәкъдимнәре эшләгән һәм керткән өчен бүләкләнергә мөмкин. Хезмәт коллективларын бүләкләү өчен түбәндәге юбилей даталары билгеләнә: 20 ел һәм алга таба һәр ун ел.

Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә тәкъдим иткәндә, югарыда күрсәтелгән эзлеклелек кулланылмый.

2.3. Бүләкләүләр министр урынбасарларының, структур бүлекчәләр җитәкчеләренең үтенече буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министры боерыгы белән башкарыла.

2.4. Бүләкләүгә тәкъдим ителә торган хезмәткәрне бүләкләү турында бөтен төр милектәге оешмалар коллективларының үтенече министрга бүләкләүгә кадәр бер айдан соңга калмыйча җибәрелә. Үтенечкә тәкъдим ителә торган формасы әлеге Нигезләмәгә Кушымтада бирелә трган бүләкләү кәгазе беркетелгән булырга тиеш. Бүләкләү кәгазендә кандидатның конкрет казанышлары, оешма (орган) эшчәнлеге өлкәсенә керткән шәхси өлеше турында мәгълүматлар күрсәтелгән булырга тиеш.

## III. ВЕДОМСТВО БҮЛӘКЛӘРЕ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ ТӘРТИБЕ

3.1. Ведомство бүләге белән бүләкләү Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

3.2. Ведомство бүләге белән бүләкләү тантаналы шартларда башкарыла, кагыйдә буларак, бүләкләү турында боерык чыкканнан соң 6 айдан соңга калмыйча, бүләкләнүченең эш (хезмәт) урынында.

3.3. Күкрәк билгеләре һәм аларга таныклыклар, Почет грамоталары, Рәхмәт хатлары, ведомство бүләген тапшыру Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры (алга таба – министр) яки министр урынбасарлары тарафыннан башкарылмаган шартта,  эшчене (хезмәткәрне) бүләкләүгә тәкъдим иткән оешмаларның (органнарның) вәкилләренә бирелә.

3.4. Яңа уңышлар өчен чираттагы ведомство бүләге белән бүләкләү үткән бүләкләүдән соң ике елдан иртәрәк була алмый.

3.5. Министрлыкның Почет грамотасы, Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән хезмәткәренә хезмәткә түләүләрнең билгеләнгән фонды чикләрендә бер вазыйфаи оклад күләмендә бер генә тапкыр акчалата бүләк бирелә.

3.6. Ведомство бүләге белән бүләкләнүченең хезмәт кенәгәсенә бүләкләү турында язу языла.

3.7. Ведомство бүләген яки аңа таныклыкны югалткан очракларда, Министрлык бүләкләү фактын раслый торган белешмә бирә. Ведомство бүләкләренең дубликатлары бирелми.

3.8. Ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән затларны исәпкә алуны Министрлык гамәлгә ашыра.

## IV. ВЕДОМСТВО БҮЛӘКЛӘРЕ ТАСВИРЛАМАСЫ

4.1. Медаль тасвирламасы.

Медаль 30 мм диаметрлы түгәрәктән гыйбарәт. Медальнең алгы ягында үзәктә Министрлык бинасы сурәтләнгән, аның астында ике юлда «С ЛЮБОВЬЮ К ПРИРОДЕ» дигән язу. Медальнең каймасы буйлап үсемлек орнаменты ясалган, ул өске өлештә  лалә чәчәге белән бүленгән.

Медальнең икенче ягында һәркайсы ике юллык язулар урнаштырылган – «А.И. Щеповских исемендәге медаль» һәм «Медаль имени А.И. Щеповских», алар түгәрәк үзәгендәге үсемлек орнаменты белән үзара аерыла.

Медаль элмәк һәм боҗра ярдәмендә  25х17 мм үлчәмле турыпочмаклы, яшел, ак һәм кызыл төсле горизонталь сызыклы муар тасма белән тышланган колодка белән тоташа. Ак сызык тасма киңлегенең 1/15 өлешен тәшкил итә һәм бертигез киңлектәге яшел һәм кызыл сызыклар арасында урнашкан.

Медаль җиздән эшләнгән, металлның төсе – алтын.

Медальнең тулы төсле сурәттәге макеты беркетеп бирелә.







4.1.1. Медальгә таныклык тасвирламасы.

Таныклык бумвинил тышлыктагы яшел төстәге кенәгәдән гыйбарәт. Таныклыкның үлчәме: ябылган хәлдә 75 мм x 105 мм, ачык хәлдә –150 мм x 105 мм.

Таныклык тышының алгы ягына өске өлешнең үзәгенә Татарстан Республикасы Дәүләт гербының 18 мм диаметрлы сурәте төшерелә. Герб астында рус телендә «Министерство экологии и природных ресурсов Республики Татарстан» дигән язу, ул баш хәрефләр белән 8 үлчәмле калын Times New Roman шрифты белән башкарыла. Астарак рус телендә баш хәрефләр белән 14 үлчәмле калын Times New Roman шрифты белән башкарылган «Удостоверение» дигән язу. Астарак «к медали» дигән язу, ул юл хәрефләр белән 12 үлчәмле калын Times New Roman шрифты белән башкарыла. Астарак «имени А.И. Щеповских» дигән язу, юл хәрефләр белән 12 үлчәмле калын Times New Roman шрифты белән башкарыла. Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтен һәм язуларны төшерү алтын белән башкарылган.

Таныклыкның эчке сул һәм уң якларына (җәелгән хәлдә) текстлы бланк-өстәмә бит ябыштырыла. Таныклыкның эчке сул ягында А.И. Щеповских исемендәге медальнең 25 мм x 45 мм үлчәмле сурәте урнаша, аның астында бүләкнең баш хәрефләр белән 12 үлчәмле калын Times New Roman шрифты белән башкарылган «Медаль» атамасы урнаша. Астарак юл хәрефләр белән 12 үлчәмле калын Times New Roman шрифты белән башкарылган «имени А.И. Щеповских» дигән язу.

Таныклыкның эчке уң ягында кенәгәнең үзәгендә түбәндәге сүзләр урнаша:

- «Удостоверение» һәм таныклыкның тәртип номеры;

- таныклык бирелә торган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

- «в соответствии с приказом Министерства экологии и природных ресурсов Республики Татарстан» от «___» __________201____ № ______


«награжден(а) медалью имени А.И. Щеповских».

Астарак сул кырдан «Министр» сүзе урнашкан һәм шул ук юлда уң кырдан күрсәтелә: (подпись)/(Ф.И.О.) министра.

Министрлыкның герблы мөһере сул почмакта урнаша.

Өстәмә биттәге язулар югары сыйфатлы төсле басмалы принтерда башкарылырга тиеш.

Таныклыкның төсле сурәттәге макеты теркәп бирелә.




4.2. Күкрәк билгесе тасвирламасы.

Күкрәк билгесе җиздән ясалган, эмаль һәм сумаладан эшләнгән каплама белән, 25 мм диаметрлы түгәрәк формасында.

Түгәрәк фонында яшел төстәге агачның (имән) эре буялыш белән башкарылган шартлы сурәте ясалган һәм аның астында - аскы өлештә турыпочмаклык эчендә «РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» дигән язу. Түгәрәк «ОТЛИЧНИК ОХРАНЫ ПРИРОДЫ» дигән язулы бокра эченә алынган.

Файдаланыла торган эмаль төсләре – ак, кызыл, яшел, кара.

Билгенең дизайны – ике дәрәҗәле: өске дәрәҗә – металл, ком ыргыткыч белән эшкәртелгән.

Барлык язулар кара төс белән башкарылган.

«Отличник охраны природы Республики Татарстан» язуының хәреф үлчәмнәре: «Отличник охраны природы» - 2 мм; «Республики Татарстан» - 1,8 мм.

Беркеткеч – цанга “күбәләк” каптырма.

Колодканың икенче ягында күкрәк билгесен киемгә беркетү өчен булавка бар.

Билгенең тулы төсле сурәтле макеты теркәп бирелә.




***М 1:1***

**Размер значка25х25 мм**

4.2.1. Күкрәк билгесенә таныклык тасвирламасы.

Таныклык бумвинил тышлыктагы яшел төстәге кенәгәдән гыйбарәт. Таныклыкның үлчәме: ябылган хәлдә 75 мм х 105 мм, ачык хәлдә –150 мм х 105 мм.

Таныклык тышының алгы ягына өске өлешнең үзәгенә Татарстан Республикасы Дәүләт гербының 18 мм диаметрлы сурәте төшерелә. Герб астында рус телендә баш хәрефләр белән 8 үлчәмле ярымкалын Times New Roman шрифты белән башкарылган «Министерство экологии и природных ресурсов Республики Татарстан» дигән язу. Астарак рус телендә баш хәрефләр белән 14 үлчәмле ярымкалын Times New Roman шрифты белән башкарылган «Удостоверение» дигән язу. Астарак юл хәрефләр белән 12 үлчәмле ярымкалын Times New Roman шрифты белән башкарылган «к нагрудному знаку» дигән язу. Астарак баш хәрефләр белән 12 үлчәмле ярымкалын Times New Roman шрифты белән башкарылган «Отличник охраны природы Республики Татарстан» дигән язу. Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтен һәм язуларны төшерү алтын белән башкарылган.

Таныклыкның эчке сул һәм уң якларына (җәелгән хәлдә) текстлы бланк-өстәмә бит ябыштырыла. Таныклыкның эчке сул ягында «Отличник охраны природы Республики Татарстан» күкрәк билгесенең 25 мм диаметрлы сурәте урнаша, аның астында күкрәк билгесенең баш хәрефләр белән 10 үлчәмле ярымкалын Times New Roman шрифты белән башкрылган «Отличник охраны природы Республики Татарстан» дигән атамасы урнаша.

Таныклыкның эчке уң ягында кенәгәнең үзәгендә түбәндәге сүзләр урнаша:

«Удостоверение» һәм таныклыкның тәртип номеры;

- таныклык бирелә торган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

«в соответствии с приказом Министерства экологии и природных ресурсов Республики Татарстан от «___» __________20____ № ______»

«награжден(а) нагрудным знаком «Отличник охраны природы Республики Татарстан».

Астарак  сул кырдан «Министр» сүзе урнашкан һәм шул ук юлда уң кырдан күрсәтелә: (подпись)/(Ф.И.О.) министра.

Министрлыкның герблы мөһере сул почмакта урнаша.

Өстәмә биттәге язулар югары сыйфатлы төсле басмалы принтерда башкарылырга тиеш.

Таныклыкның тулы төсле сурәттәге макеты теркәп бирелә.




4.3. Почет грамотасы.

Почет грамотасы тыгызлыгы 145 г/кв.м.-дан кимрәк һәм 175 г/кв.м.-дан артыграк булмаган  кәгазьдә эшләнә. Почет грамотасының үлчәмнәре: киңлеге – 210мм, биеклеге - 297мм. Почет грамотасын бизәү Татарстан Республикасының Рәсми һәм эшлекле стиль элементлары төзелеше һәм файдалануның визуаль стандартлары паспорты нигезендә төсләр гаммасы белән төгәл туры китереп башкарыла.

4.4. Рәхмәт хаты.

Рәхмәт хаты тыгызлыгы 145 г/кв.м.-дан кимрәк һәм 175 г/кв.м.-дан артыграк булмаган кәгазьдә эшләнә. Үлчәмнәре: киңлеге – 210мм, биеклеге - 297мм. Рәхмәт хатын бизәү Татарстан Республикасының Рәсми һәм эшлекле стиль элементлары төзелеше һәм файдалануның визуаль стандартлары паспорты нигезендә төсләр гаммасы белән төгәл туры китереп башкарыла.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының ведомство бүләкләре турында нигезләмәгә кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

______________________________
(республика)

______________________________
(район, шәһәр)

______________________________
(ведомство бүләге төре)

БҮЛӘКЛӘҮ КӘГАЗЕ

1. Фамилия, исем, атасының исеме ______________________________

______________________________

2. Вазыйфа, эш, хезмәт урыны (бүлекнең, башка бүлекчәнең, учреждениенең, оешманың, министрлыкның, дәүләт комитетының, ведомствоның төгәл атамасын күрсәтергә)

______________________________

______________________________

______________________________

3. Җенес ______________ 4. Туу датасы һәм урыны ______________________

5. Белем ______________________________

______________________________

6. Гыйльми дәрәҗә,  гыйльми исем, махсус исем ______________________________

______________________________

7. Нинди дәүләт һәм ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән һәм бүләкләү даталары:

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

___

8. Йорт адресы: ______________________________

Гомуми эш стажы ____________________ Тармакта эш стажы ____________________

Бу коллективта эш стажы ______________________

9. Бүләкләнүченең конкрет аерым хезмәтләрен күрсәтеп, характеристика:

Кандидатура хезмәт коллективы советы (җыелышы) тарафыннан тәкъдим ителде

______________________________

(учреждение, оешма атамасы, тикшереп фикер алышу датасы, беркетмә №)

Тәкъдим ителә ______________________________

(бүләкләү төре)

| Оешма, учреждение җитәкчесе | | Хезмәт коллективы советы (җыелышы) рәисе |
|---|---|---|
| ______________________ | М.У. | ______________________ |
| (имза) | | (имза) |
| ______________________ | | ______________________ |
| (Ф.И.О.) | | (Ф.И.О.) |